
Бүгенге санда



Шәһәрдә тәртип өчен кем җаваплы? 2 бит.


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 23 октябрь 2015 ел

№78 (10607)


**24 октябрьгә һава торышы:** болытлы һава, урыны белән карлы яңгыр, җил көньяктан, 3-4 м/с; температура көндез +1°С, төнлә -1°С


**Редакциядә – Әбунәче көне**

*Бүген редакциянең реклама бүлегендә Әбунәче көне бара. Киләсе яртыеллыкка **"Дуслык"ка** язылучы һәр әбунәче редакциядән тыйнак кына булса да призлар алып китә. Сез әле язылырга өлгермәдегезме? Әле соң түгел, без Сезне көн дәвамында көтәбез!*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.


### ИРТӘГӘ – ЯРМИНКӘ

Шимбә, 24 октябрьдә, Гыйматдинов урамының үзәк өлешендә авыл хуҗалыгы ярминкәсе үтәчәк. Ярминкәдә шәхси ярдәмче хуҗалыклар, фермерлар, авыл хуҗалыгы предприятиеләре, авыл җирлекләре чамалы бәяләрдән киң ассортимент тәкъдим итәчәкләр. Оештыручылар әйтүенчә, ярминкәдә шикәр комының килограммы 46, бәрәңге 12, эре терлек ите 270-300, сөтнең литры 28 сум торачак, бөртек, яшелчәләр дә базардагыдан арзанрак булачак. Бу юлы фермерлар ярминкәгә тере йорт хайваннары да алып чыкмакчы. Ярминкә иртәнге 7дән башлана.

Шул уңайдан иртәнге 6дан көндезге 12гә кадәр Гыйматдинов урамының 1нче мәктәптән элеваторга кадәрге машиналар юлы ябык булачак.

### БЕЗДӘ МИНИСТР БУЛЫП КИТТЕ

Чәршәмбе көнне эш визиты белән районда ТРның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин булып китте. Район башлыгы Равил Кузюров озатуында алар күтән түгел төзелгән Кече Камышлы юлын карадылар. Аннан Төньяк – Көнчыгыш микрорайоны урамнары буйлап үттеләр, быел биредә юллар төзелеше буенча масштаблы эшләр үткәрелде. Визит барышында шәһәрнең әйләнеч юлларын да карадылар. Очрашу барышында Ленар Сафин һәм Равил Кузюров район һәм шәһәр транспорт челтәре үсеше перспективалары турында фикер алыштылар.

# Хәерле иртә һәм имин юллар!



Автор фотосы

Анатолий Дмитриев һәм Валерий Николькин – „Нурлат УТТсы"ның иң яхшы хезмәткәрләре

**Технологик транспорт идарәсендә хезмәт куючы машина йөртүчеләр Анатолий Дмитриев һәм Валерий Николькинның эш көне кул кысышудан һәм хәерле юл теләүдән башлана.**

Алар УТТда гына түгел, составына әлеге предприятие кергән "Татспецтранспорт" идарәче компаниясендә дә яхшылар исәбендә саналалар. "Татра" йөртүчесе Анатолий Дмитриевның портреты Мактау тактасында бер генә ел эленеп тормый. 24 еллык машина йөртү стажының 10 елын УТТга биргән ул. Үзенең "КамАЗ" машинасында буровойга кызыл балчык измәсе ташучы Мактаулы нефтьче Валерий Николькин кебек үк, җитәкчелек тарафыннан берничә тапкыр бүләкләнгән. Валерий Николькин бүген тәҗрибәле машина йөртүче генә түгел, яшьләрнең остазы да: УТТда ул предприятие оешкан көннән алып – 35 ел эшли. Авыр техника йөртүче әлеге хезмәткәрләр шушы еллар эчендә меңләгән километр юл узганнар, һәм, предприятие җитәкчесе сүзләренә караганда, алар хезмәттәшләре арасында да, җитәкчелек тарафыннан да хөрмәт казанган кешеләр.

Нурлат УТТсында барлыгы 633 кеше эшли, шуларның 501е – машина йөртүчеләр. Коллектив транспорт чараларын куллану буенча елның иң авыр һәм киеренке саналган соңгы кварталына аяк басты. Юл һәлакәтләре һәм фаҗигаларсыз эшләү өчен машина йөртүчеләрдән зур игътибарлылык сорала.

– Коллективта зур һөнәри тәҗрибә тупланган, – ди Нурлат УТТсының башкарма директоры Илдар Галиев. – Нефть чыгару, бораулау, төзелеш объектларында башкарылган эшләрнең сроклары, сыйфаты хезмәткәр җаваплылыгына бәйле булуын һәрберсе аңлый. Ә эшебезнең нәтиҗәлелеге коллективның эшкә сәләтен һәм куелган максатларга ирешү өчен барысын да эшләвен күрсәтә.

Быел Нурлат УТТсы оешуга 35 ел тулды. Мондый предприятие өчен, кем әйтмешли, бу үсмер чор гына. Димәк, алда әле – предприятиегә стабильлек һәм финанс тотрыклылыгы китерүче яңа максатлар, километрлар.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

*Теманың дәвамы 3нче биттә.*

РӘСМИ

# Сессия оештыру мәсьәләләрен карады

**Нурлат районы советының кичә үткән икенче сессиясе оештыру мәсьәләләрен карауны дәвам итте.**

Сессиянең көн тәртибе буенча, конкурс нигезендә, ачык тавыш бирү юлы белән район башкарма комитеты җитәкчесе итеп бертавыштан Әсгать Касыйм улы Габдуллин билгеләнде. Икенче кандидат – Наил Фазлыев үз кандидатурасын алуы турында хәбәр итте. Сессияне алып баручы район советы рәисе Равил Кузюров Әсгать Касыймовичны котлап, уңышлы эш теләде. Аннан соң беренче сессиядә оештырылган район советы даими комиссияләре составы расланды. Сессиянең шуннан соңгы мәсьәләләре буенча информацияне районның финанс-бюджет палатасы рәисе вазифаларын башкаручы Асия Әһлиуллина бәян итте. Депутатлар 2013 елның 22 октябрендә кабул ителгән "Нурлат муниципаль районында бюджет процессы турында"гы һәм 2005 елның 10 ноябрендәге "Аерым төр эшчәнлек өчен вмененный керемгә бердәм салым рәвешендә салым системасын гамәлгә кертү турында"гы район советы карарларына үзгәрешләр керттеләр. Соңгы көн тәртибе буенча район территориаль сайлау комиссиясенә билгеләү өчен Урта Камышлы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Надежда Сергеева кандидатурасы тәкъдим ителде.

Сессия эшендә Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасары Рәис Гомәров, ТР Дәүләт Советы депутатлары Илгиз Салихов һәм Шамил Яһудин катнаштылар.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

### "СӨЙКЕМЛЕ ЕЛМАЮ" КОНКУРСЫ



*Шәһәрнең 1нче мәктәбендә 1нче В сыйныфында укучы Амалия Галләмова ни өчен шулай ихлас елмая дисезме? Сәбәбе гади: бу көннәрдә Татарстанда яшәүче барлык беренче сыйныф укучылары сыман ук мәдәни көндәлеккә ия булды ул. Мәктәптә укучы 70тән артык беренче сыйныф укучысы ике телдә төсле рәсемнәр һәм кызыклы биремнәр белән бизәлеп ясалган көндәлекне Амалия кебек шатланып кабул итте. Мәдәни көндәлек яңа белемнәр, экскурсияләр, сәяхәтләр, мәдәни чараларга да юл ача бит.*

**Газетаның электрон версиясен nurlat-tat.ru сайтында укыгыз**

# Сан алу халык өчен кирәк

**Бу көннәрдә районда микро сан алу тәгәлләнеп килә. Әмма статистларга тынычланырга юк: 2016 елда авыл хуҗалыгы сан алуы көтелә бит.**




НАИЛӘ АЛИЕВА БЕЛӘН ВЕНЕРА ХӘЛИМОВА МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ КАЗАНГА ТАПШЫРА

20 октябрь Бөтендөнья статистлар көне иде. Әлмәт дәүләт статистикасының Нурлат бүлеге хезмәткәрләре өчен бу – гадәти эш көне. Бер-берләрен бәйрәм белән котлаштылар да янә үз эшләренә – саннар, чагыштырулар, тикшеренүләр дөньясына кереп чумдылар. Ә филиалның баш белгече Наилә Алиева җыенып, Чулпан авылына юл алды. Чулпан – районда берничә урамы октябрьдә бөтен Россия буйлап үткәрелә торган микро сан алуга сайлап алынган участокларның берсе, һәм сан алу кампаниясе башланганнан бирле баш белгеч бирегә атнасына берничә тапкыр килеп китә.

– Микро сан алуга Чулпан авылының Заречная, Шоссейная, Мәктәп, Муса Җәлил, Тукай урамнарыннан 160 йорт хуҗалыгы җәлеп ителде, - ди Наилә Алиева. – Сан алучы әлеге йортларның барысын да йөреп, социаль-демографик тикшеренү үткәреп чыкты. Ул планшетка туплаган мәгълүматларны Казанга җибәрәчәкбез.

Сан алучы белән баш белгеч авыл җирлеге башкарма комитетында очрашалар. Сан алучы Венера Хәлимованың планшетыннан мәгълүматларны күчерү бик озак вакытны алмый. Шул арада Венера белән сөйләшеп алырга өлгерәбез. Венера – яшь әни, баласы белән декрет ялында утыра. Сан алуда да беренче генә катнашуы. Әмма халык арасында эшләү ошаган үзенә.

– Кыенлыклар булмады диярлек. Сан алуның нечкәлекләренә статистика бүлегендә махсус укуларда өйрәттеләр. Башта планшетта тест рәвешендә күнегүләр үттем, 3 октябрьдән йортларга йөри башладым. Үзем шул авылныкы булгач, халык – таныш. Ул як урамнарда күбрәк олы яшьтәгеләр яши. Сан алуларда беренче генә катнашулары түгел, җитди кабул итәләр, барлык сорауларга да тулы җаваплар бирделәр. Дөрес, авылдан читкә йөреп эшләүчеләр дә шактый, аларга берничә кат та барырга туры килде, әмма эшемне вакытында тәгәлли алдым, - ди сан алучы.

Ә Наилә Алиева Чулпаннан һәм шәһәрдәге участоктан сан алучы Нина Гыйләҗевадан җыелган мәгълүматларның соңгыларын Казанга юллаячак. Микро сан алу 31 октябрьгә кадәр дәвам итсә дә, Нурлатта сан алучылар аны ике участокта да 20 октябрьгә кадәр тәгәлләделәр. Хәзер инде нәтиҗәләрне көтәсе кала.

– Микро сан алу вакытында тупланган мәгълүмат беркая да таратылмый, ул торак, салым яки башка дәүләт органнарына да бирелми, - ди баш белгеч. – Халыкның микро сан алуы мәгълүматлары бары таблицалар рәвешендә генә кулланылачак, ә нәтиҗәләре буенча галимнәр эшләячәк һәм хакимият органнарына рекомендацияләр бирәчәкләр. Микро сан алу башлыча 2020 елгы сан алуга әзерлек кысаларында үткәрелсә дә, бу сайлап алу тикшеренүе илдә яшәүче халык турында актуаль социаль-демографик мәгълүматлар алырга ярдәм итә бит. Ә алар Россия хөкүмәтенә, барлык дәрәҗәдәге башкарма хакимият органнарына демографик хәлне алга таба яхшырту буенча кабул ителгән өстәмә чараларның нәтиҗәлелеген билгеләргә һәм яңаларын эшләргә булыша.

**Бөтенроссия авыл хуҗалыгы сан алуы 31,4 мең аграр, 29,6 мең микрооешма, 55 мең шәхси эшмәкәр, 167,6 мең фермер хуҗалыгы, 20 миллионнар чамасы шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык ширкәтләренә кагылыр дип көтелә.**

## "АВЫЛДА – ТӘРТИП, ИЛДӘ – МУЛЛЫК"

Киләсе елның 1 июленнән 15 августына кадәр дәвам итәчәк Бөтенроссия авыл хуҗалыгы сан алуы әнә шундый шигарь астында үтәчәк. Аңа әзерлекнең барышы һәм бу мөһим кампаниянең үзенчәлекләре хакында әңгәмәбезне Наилә Алиева белән дәвам итәбез.

– Бөтенроссия авыл хуҗалыгы сан алуы – бик җитди һәм мөһим кампания. Ул авыл хуҗалыгы, аның бүгенге торышы турында актуаль статистика алырга, илнең аграр потенциалын билгеләргә, авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә, ярдәм программаларын дөрес юнәлтүгә ярдәм итәчәк. Элегрәк мондый масштабтагы авыл хуҗалыгы сан алуы 2006 елда үткәрелгән иде.

**– Аңа әзерлек эшләре ничек бара?**

– Авыл хуҗалыгы сан алуын үткәрү буенча махсус комиссия төзелде. Аның белән район башлыгы Равил Кузюров җитәкчелек итә. Комиссия 18 кешедән тора, анда авыл хуҗалыгына кагылышы булган структураларның җаваплы затлары белән бергә, хокук саклау органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан да вәкилләр бар. Әзерлек кысаларында 8 теркәүче шәһәрдәге шәхси ярдәмче хуҗалыкларның санын алып чыкты, шәһәрдә алар 5147әү. Авыл җирлекләре дә авыллардагы йорт хуҗалыклары саны турында мәгълүмат тупладылар. Авылда барлыгы 9737 йорт хуҗалыгы исәпләнә. Бу мәгълүматлар Бөтенроссия сан алуында катнашачак объектларны исемлеккә кертү өчен кирәк. Сан алуда исә 463 йортта бер сан алучы эшләр дип фаразлана, аларны халык арасыннан җәлеп итәчәкбез. Сан алуга әзерлек кысаларында шәһәр тирәсендәге бакчачылык ширкәтләрендәге дача участокларын да барлап чыктык.

**– Сан алуда нинди сораулар биреләчәк?**

– 2006 елдагы сан алуыннан аермалы буларак, программага яңа темалар кертелгән. Алар арасында хуҗалык алып баруның заманча методлары, максатчан кредитларны файдалану, федераль һәм төбәк бюджетларыннан дотацияләр алуга кагылышлылары булыр дип планлаштырыла. Исемлеккә элеккечә җир мәйданнары, халыкның мәшгульлеге, терлек һәм кош-кортның саны, җиләк-җимеш бакчаларының мәйданнары һәм башка сораулар да кертелгән.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт.**

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

**МӘГЪЛҮМАТ**

**2016 елдагы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы сан алуы дәүләткә 13 миллиард сумга төшәчәк. Сумма сан алу һәм мәгълүматларны эшкәртүгә китәчәк вакыт – 2016-2018 елларга билгеләнгән.**

# Кайда да сынатмыйлар

25 ОКТЯБРЬ – АВТОТРАНСПОРТЧЫЛАР КӨНЕ

**Шәһәр, шәһәрара, шәһәр яны һәм заказ юнәлешендә Нурлат пассажирларына хезмәт итүче "Нурлат АТП"сы автобуслары соңгы елларда Халыкара спорт чараларында да эшли.**




ВЛАДИМИР ЧЕБОТАРЕВКА ИРТӘН ПУТЕВКАЛАРНЫ ТАМАРА КУЗЬМИНА БИРӘ

Быел Казанда узган спортның су төрләре буенча Чемпионатта эшләгән 326 шоферның берсе янә Нурлат АТПсы шоферы Владимир Чеботарев иде. 34 ел әлеге предприятиедә автобус шоферы булып эшләүче Владимир Кузьмич бирегә армиядән кайткач килә. Армия сафларында да автобус иярләгән яшь белгечне предприятиедә бик тиз үз итәләр.

- 1981 елда АТП нефть оешмаларына хезмәт күрсәтә иде, - ди Владимир Чеботарев. – Менә шулай әлеге җәмгыятькә кереп киттем һәм бер генә дә үкенмим. 10 еллап нефтьчеләргә хезмәт күрсәттек, аннан пассажир маршрутына күчтем. Шәһәр, шәһәрара рейсларда эшли башладым. 45 урынлы чех автобусы "Кароса"ны, Россиядә җитештерелгән "Нефаз" автобусларын иярләдем. Хәзер исә чит илдә эшләнгән заманча "Хундай" руле артында. Яңа автобус белән Универсиадада, Чемпионатта да эшләргә насыйп булды. Дөрес, җиңел түгел, халык белән эшләргә, пассажирларның иминлеген дә тәэмин итәргә кирәк.

Халыкара чараларга хезмәт күрсәтүгә бары үз эшләренең осталарын гына алалар, билгеле.

- Володя бик зур сайлап алу туры узды, - ди җәмгыять җитәкчесе Идрис Кәримов. – Яшь рамкалары да, шоферның юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен, беренче ярдәм күрсәтә, инглиз телен, этикет кагыйдәләрен белүе, һәлакәтләрсез эшләве дә исәпкә алынды. Шул турны узгач кына махсус укулар үтте ул.

- Чемпионат вакытында, нигездә, чит ил спортчыларын һәм матбугат хезмәткәрләрен йөртергә туры килде, - ди автобус шоферы. – Нигездә, Португалия, Африка илләреннән килгән гражданнар белән эшләдем.

61 еллык тарихы булган предприятие бүген 54 кешегә эш урыны биргән. Транспорт паркында исә ике дистәдән артык берәмлек техника исәпләнә. Хәлдән килгәнчә, автобус паркын да яңартып торырга тырышалар.

Предприятиенең уңышлы эшләвендә кеше факторы зур роль уйный.

- Коллективта эшләүче һәр хезмәткәр тәҗрибәле һәм зур стажга ия, - ди Идрис Габделбәрович. – Күбесе миллионлаган километр юллар узган.

Предприятиегә тугрылыклылар исемлегендә өлкән диспетчер, ягулык салучы һәм склад мөдире булып эшләүче Тамара Кузьмина да бар, ул биредә 27 ел эшли икән инде.

- Шул еллар эчендә табельчы, кондуктор хезмәтләрен дә башкардым. Хәзер берүземә өч вазифа, - ди Тамара елмаеп.

Эш иртәсе иртәнге 5тән башланса да, ул зарланырга яратмый.

- Бик дус коллективта эшлим. Гомерем буе ир-атлар арасында булдым. Өйдә тормыш иптәшем, ике улым, оныгым Макар көтә. Шуңа күрә ир-ат һөнәрен сайлаганмындыр инде.

АТП коллективы район тормышында да актив катнаша. Төп билгеләнешләре – транспорт хезмәтләре күрсәтүдән тыш, алар шәһәр йөзен матурайтуга да үз өлешләрен кертәләр. Әлеге бистәдә яшәүче нәни нурлатлылар АТП территориясендәге балалар мәйданчыгын күптән үз итте инде. "Тиенкәй" балалар бакчасы нәниләре дә автотранспортчыларның ярдәменә таянып яши. Коллектив үз футбол командасы булуы белән дә горурлана.

Зилия **ӘКСАНОВА**

САК БУЛЫГЫЗ!

# Авырудан прививка коткара

**Төлкеләрнең көзге активлыгы күзгә ташлана.**

Һәм бу юкка түгел. Чөнки йогышлы котыру авыруы соңгы араларда аеруча куркыныч тудыра. Шуңа да 9 октябрьдә котыру авыруы буенча эпизоотик хәлне яхшырту һәм шулай ук котыру авыруын профилактикалау максатыннан район башкарма комитеты “2015 елда Нурлат районында котыру авыруын профилактикалау чараларын көчәйтү турында” карар кабул итте.

Дәүләт ветеринария инспекторы Ләйсән Ишкнеева әйтүенчә, 2015 елда районда 27 кеше хайваннар тешләүдән зыян күргән, аларның барысына да тиешле ярдәм күрсәтелгән һәм котыруга каршы вакцинация үткәрелгән.

– Нурлат районында төлкеләрнең үрчүен киметү максатыннан 132 төлке атылды, шулай ук хуҗасыз эт һәм мәчеләр тотыла. Котыру авыруы, нигездә, кызыл төлкедән тарала, әмма эт һәм песиләр, шулай ук терлекләр дә авыру чыганагы булырга мөмкин. Инфекция хайваннардан кешегә тешләгәндә яки зарарланган тиресегә селәгәйләре эләккәндә күчә. Котыру авырулы дип саналган хайваннарның тешләвенә дучар булган кешеләрнең 40 проценттан артыграгы 15 яшькә кадәрге балалар, алар хайваннар белән курыкмыйча уйныйлар, - дип билгеләп үтә ул.

Авыруның беренче билгеләре котмәгәндә башлана: хайваннар яктылык, тавышка сизгеррәккә әйләнә, соңрак алар агрессивлана һәм кешеләрдән курыкмый башлыйлар, берникадәр вакыттан йоткылык һәм аяклары параличлана.

Сезнең тормышыгыз табибка вакытында мөрәҗәгать итүгә бәйле. Вакытында алынган прививкаларның тормышыгызны саклап калучы бердәнбер нәтиҗәле чара икәнлеген онытмагыз!

- Кешедә котыру авыруын бары профилактик прививкалар белән генә кисәтергә була, аларның нәтиҗәлелеге исә яшәү урыны буенча медицина ярдәменә никадәр тизрәк мөрәҗәгать итүгә бәйле. Шунысын да исегезгә төшерәбез: котыру авыруыннан прививкалар сезнең медицина полисыгыз булу-булмауга карамастан, түләүсез ясала. Практикада “Внуково-32” штаммыннан вакцина кулланыла, ул иммунитет булдыра. Нурлат дәүләт ветеринария берләшмәсе табиблары ел башыннан бирле 3697 сыерга, 14241 эткә, 1417 мәчегә котыруга каршы вакцина ясады. Вакцинация үткәргәндә хуҗаларның баш тартмауларын сорыйбыз, - ди Ләйсән Ишкнеева.

Валентина ВАФИНА әзерләде

БУ КЫЗЫКЛЫ

# Нурлатта Чиполлинолар тумаячак

**Швеция, Дания, Малайзия, Яңа Зеландия артыннан Россиядә дә балаларга нинди дә булса бәхетле саннар, кызыклы вакыйгалар, аббревиатуралар белән бәйле исемнәр кушу модасы тиздән тыелырга мөмкин.**

Хәзерге вакытта балаларга исем сайлауда ата-аналар тулысынча ирекле. Әмма әгәр дә “Гражданлык хәлләре актлары турында”гы законга Дәүләт Думасында әзерләнгән төзәтмәләр кабул ителә калса, Россиядә балаларны сәер исемнәр белән атап булмаячак. Алайса кемнәр генә нинди генә исем уйлап чыгармый бит. Мисал өчен, Воронежда бер ана улына ТорПут (Торжество Путина) исеме кушарга тырышкан, ЗАГС хезмәткәрләре генә шул уеннан кире кайтырга күндергәннәр. Шул ук вакытта күптән түгел генә Рязань өлкәсендә Граф һәм Принцесса туган, ә Мәскәүдә Каспер Ненаглядный һәм хәтта Лук Порей үсеп киләләр. Балаларына гадәти булмаган исем кушкан ата-аналар ни уйлаганнардыр, һәм исемнәр балаларының язмышына ничек тәэсир итәсен күзалларына китерделәр микән. Нурлатта да Амадей, Захар, Агата, Зелимхан, Али, Социалина, Сириус, Ариус, Добрыня, Елисей, Феликс, Вальтр кебек иске исемнәрне очратырга була.

– Соңгы вакытта ата-аналар балаларын гадәти исем белән атаудан курка башладылар. Алар күпчелек матур һәм яңгырашлы исемнәрдән баш тартып, үзләренчә заманага ярашлы исемнәр уйлап табарга тырышалар. Без, үз чиратыбызда, аларга исемнәрне бозарга кирәкмәгәнлеген аңлатабыз, рус һәм татар исемнәре сүзлекләре белән танышырга, исемнәрнең мәгънәләрен белергә тәкъдим итәбез, – диде районыбызның ЗАГС бүлеге начальнигы Гөлшат Евлахина. – Мин балаларга традицион исемнәр кушу яклы. Гади кеше буларак, ата-аналарның балаларына гадәти булмаган исемнәр бирүләрен дә хуплыйм. Әмма монда акыл белән эш итәргә кирәк, чөнки баланың шул исем белән гомер итәсе бар бит.

Гөлшат Евлахина сүзләренә караганда, кешеләр еш кына олыгайгач исемнәрен үзгәртергә карар кылалар. Моны статистика да раслый. Ачыкланганча, безнең районда да шундый хәлләр сирәк күренеш түгел икән.

Маргарита ЛИТТА




БЕЗНЕҢ КОНКУРС

# Бездә әкәм-төкәмнәр бар

**Конкурска газета укучыларыбыз тарафыннан җибәрелгән фотосурәтләр берсеннән-берсе кызыклырак була бара.**

Күптән түгел генә Алексей Тиманкин үрмәкүчләре белән гаҗәпләндергән иде, бу юлы Зөлфия Хуҗәхмәтова үзенең гигант әкәм-төкәмнәре белән таныштырды.

– Әкәм-төкәмнәрне быелның апрелендә безгә күршебез бүләк итте, аларны ул Карелиядән алып кайткан. Бик кечкенәләр иде. Интернетта әлеге җан ияләре турында укып, фотографияләрен карагач кызыксынып киттек, – дип сөйли Зөлфия. Ярты ел эчендә әкәм-төкәмнәр яхшы гына үскән, хәзер алар йомыркадан зуррак, әмма бу чик түгел, аларның кабырчыклары 25 см, ә гәүдәләре 30 см.га кадәр җитәргә мөмкин.

– Әкәм-төкәмнәр талымсыз, аларны урамда йөртергә кирәкми, аллергия тудырмыйлар, сусыл үсемлекләр һәм яшелчәләр яраталар. Гадәттә, мин аларга кыяр, ташкабак, алма, кәбестә һәм Кытай салаты яфраклары ашатам. Кальций белән тәэмин итү, кабырчыкларын ныгыту өчен тарттырылган йомырка кабыгы һәм туфрак бирәм.

Әкәм-төкәмнәрне бит тиресен яшәртү өчен дә кулланырга мөмкин икән. Моның өчен әкәм-төкәмне юып, чистартылган биткә җибәрергә дә, бераздан аны алып, бит тиресендәге “эзләрен” тигезләп җәяргә һәм 15 минут көтәргә кирәк. Әкәм-төкәмнәр бүлеп чыгара торган сыеклык дәвалы санала, күзәнәкләрне яңадан торгызырга ярдәм итә. Бу әле биткә бик шәп массаж да. Күпчелек кыйммәтле косметика салоннарында шундый хезмәттән файдаланырга мөмкин, ди.

– Ахатина әкәм-төкәмнәрен күзәтү кызыклы, алар белән аралашу, кулда тоту күңелгә ятышлы, тынычландыралар да. Әлбәттә, мондый җан ияләре бар кешегә дә ошап бетмәскә мөмкин. Әмма мин аларны яратам, – диде әкәм-төкәмнәрнең хуҗасы.

Гүзәлия МӘХМҮТОВА

**КЫЗЫКЛЫ ФАКТ**

**Әгәр Ахатина әкәм-төкәмнәренә төсле яшелчәләр һәм җиләк-җимеш ашатсаң, кабырчыклары төрле төскә керергә мөмкин. Мәсәлән, кызыл борыч кызыл, ташкабак һәм алма аксыл көрән сызыклар бирә.**

# “Алтын балык”та алтын балык яши

**Конкурсыбызның чираттагы катнашучылары – “Алтын балык” балалар бакчасы коллективы.**




БАЛАЛАР АЛТЫН БАЛЫК БЕЛӘН ОЧРАШУНЫ КӨТЕП АЛА

Бакчада кечкенә табигать почмагы оештырып, алар балаларда миһербанлык, кайгыртучанлык сыйфатлары тәрбиялиләр.

Бакчаның төп горурлыгы – алтын балык. Бакча символын гәүдәләндергән әлеге җан иясе балаларның чын дустына әверелгән. Беренче каттагы фойеда куелган аквариум иртән-иртүк балаларны каршы алып, үзенә җәлеп итеп тора. Балык бакчага теләмичә килгән балаларның күз яшьләрен дә киптерә, кәефләрен күтәрә, матурлыгы белән сокландырып, гүзәллеккә тартылу хисләре дә уята. Аның янында ташбака белән тутый кош урын алганнар, аларны бакчага ата-аналар алып килгән. Әлеге җан ияләрен карап-тәрбияләп торуда балалар бик теләп катнаша.

– Бу үз гаиләләрендә йорт хайваннары булмаган балаларга да җан ияләре белән күпмедер дәрәҗәдә аралашу мөмкинлеге бирә, – ди бакча җитәкчесе Алсу Рәхмәтуллина.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бу районда тере җан ияләре булган бик сирәк бакчаларның берсе. Күпчелек бакчаларның экологик почмакларында, башлыча, бүлмә гөлләре, үсемлекләр генә бар.

Гүзәл САДЫЙКОВА

# Улларына керпе бүләк иткәннәр




**Нурлаттан Дормидонтовлар гаиләсендә Симка һәм Луи кушаматлы кәрлә африка-алжир керпеләре яши.**

Әти-әниләре аларны уллары Тимур һәм Тигранга туган көннәренә бүләк йөзеннән Казан питомникларының берсеннән сатып алып кайтканнар. Ә моңа кадәр Интернеттан аңлатмалар һәм фикерләр белән җентекләп танышкан булганнар. Малайларны гадәти булмаган әлеге җан ияләре таң калдырган.

– Улларыбыз керпеләрне бик яратты, аларны карап-тәрбияләп торалар, үз-үзләрен тотышларын күзәтәләр. Алар бит холыклары, төсләре ягыннан бер-берсеннән аерылалар. Симка – сакчыл, чит кешеләрнең кулына килми, ә Луи, киресенчә, бик актив һәм аралашучан, – дип сөйли әниләре Ләйлә.

Көнкүрештә керпеләр бик талымсыз булып чыкканнар. Алар махсус ризык белән тукланалар, һәркайсының үз читлеге бар. Табигатьләре буенча керпеләр ялгызаклар. Хәер, Симка белән Луи һәрвакыт аерым яшәмиләр, алар – парлар һәм тиздән беренче балалары дөньяга килергә тиеш.

Маргарита ЛИТТА

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА


ПРАЗДНУЕМ ВМЕСТЕ!

СУПЕРЦЕНЫ

ЭССЕН ГИПЕРМАРКЕ

с 27 октября по 10 ноября



-28%

126

89.90

Цыпленок-бройлера, охлажденный, Пестречинка, 1 кг
с 27 октября по 3 ноября



Масло "Олейна" подсолнечное рафинированное, 1 л



-42%

191

109.90

Продукт сырный "Фетакса" 60 %, Хохланд, 400 г



-40%

499

299

Одеяло 1,5 и 2 спальное, синтепон



-6

199

Подарочный набор Дав: шампунь+бальзам для волос+гель для ду

Цены указаны за единицу товара в рублях с учетом скидки и действительны с 27 октября по 10 ноября 2015 г. по карте «ЭССЕН. Моя Семья» в гипермаркетах ЭССЕН. Изобр товара может отличаться от представленного в гипермаркете. Количество товара ограничено. Подробности акции и наличие товара уточняйте в гипермаркете ЭССЕН.



**31 ОКТЯБРЯ И 1 НОЯБРЯ 2015 ГОДА**

в здании типографии, ул. К. Маркса, 19 фирма **«РОЛЕ СОЛЕ»** проводит выставку-продажу мужских и женских пуховиков, Алясок и курток с климат-контролем от фабрик г. Санкт-Петербург. Новая коллекция.

**Ждем вас с 9.00 до 18.00.**



**29 октября с 14 до 15 ч.**
**в Ц.Р. Аптеке № 94 – ул. Гагарина, 10**

**Слуховые аппараты**

**от 3500 до 17000 р.** (Россия, Дания, Германия)
усилители звука 1500-2500 руб. Батарейки, вкладыши – 30 руб. ***Только сегодня скидки пенсионерам до 2000 руб!****
**выезд по району - тел- 89225036315**
*скидка предоставляется 29.10.2015 г.
Подробности у консультантов..
Организатор ИП Коробейникова Е.М.
Св № - 305183220300021
**ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА**

Реклама



ArtDesign* студия рекламы

*г. Нурлат, ул. Школьная*
*тел.*
*8*
*emai*

- изготовление печатей и штампов за 1 час;
- вывески, объемные буквы, печать баннеро
- планы эвакуации;
- сувенирная и наградная продукция;
- оперативная полиграфия;
- лазерная гравировка;
- дизайн и макетирование и многое другое.

В честь 5 -л
с 21 октября п
2015 года м
скидку 1

* Арт Дизайн
** Подробности по телефону

Организатор ООО «



***БАВАРСКИЕ ОКНА***

Тепло и уют Вашего дома.

- Пластиковые окна, лоджии, двери;
- Металлические и межкомнатные двери;
- Арки
- Горизонтальные и вертикальные жалюзи;
- Автоматические ворота;
- ОСП, гипсокартон;
- Теплицы
- Натяжные потолки

**СКИДКИ – 1000 руб. на КАЖДОЕ изделие ***
**МОСКИТНАЯ СЕТКА В ПОДАРОК**
Кредит**
Доставка и выезд инженера по замеру по г.Нурлат осуществляется - БЕСПЛАТНО!
Наш адрес: г.Нурлат ул.Советская, 92.
Тел.89370085308, 89274136982, 2-04-68
*скидки действуют на пластиковые изделия в период с 01.10.15 по 31.10.15 г. Условия у продавцов. Организатор: ИП Чванова Л.П.
**кредит предоставляется АО «ОТП Банк».

Реклама



·ВСЕ ДЛЯ БАНИ вагонка, двери. Полы, элементы лестниц. Печи, дымоходы, камни и др.
Т. 8-9274-12-86-71.



**АЯК КИЕМНӘРЕН РЕМОНТЛАУ**
**29 ОКТЯБРЬДӘ**
**9.00-18.00** сәг.тә
**Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү йортында**
*(Мәктәп ур., 8)*
**КИРОВ**
**АЯК КИЕМНӘРЕ ФАБРИКАСЫ**
**аяк киемнәрен ремонтка кабул итә.**
*Алдан түләргә кирәкми.*
Аяк киемнәрегезгә
ИКЕНЧЕ ТОРМЫШ бүләк итегез.



**26 ОКТЯБРЯ** В ЗДАНИИ ТИПОГРАФИИ (УЛ. К.МАРКСА, 19) УЛЬЯНОВСКАЯ ОБУВНАЯ ФАБРИКА ПРОВОДИТ ВЫСТАВКУ-ПРОДАЖУ ОБУВИ ИЗ НАТУРАЛЬНОЙ КОЖИ (ПР-ВО УЛЬЯНОВСК, БЕЛАРУСЬ, КАЗАНЬ).



**Отделка уличных откосов, теплых откосов, подоконники, отливы, регулировка окон.**
**Т. 8-9874-19-83-41.**



**ОЦМП «Классик»**
*реализует ПРОФНАСТИЛ оцинкованный, окрашенный, под искусственный камень, под дерево. Гладкий лист. С-8, С-10, Сс-10, СШ-10, МП-20, С-21, НС-35, НС-44.*
***Металлочерепица:***
*- «Супермонтерей» - «Каскад» - «Классик»*
**Сайдинг металлический:**
- «Корабельная доска»
- «Блок-хаус»
- «Софит» - под дерево.
Доборные элементы, водосточная система. Евроштакетник.
**ВСЕГДА НИЗКИЕ ЦЕНЫ!**
**Наш адрес: г.Нурлат, ул. Заводская, 1А, напротив ЖБИ**
**Т.: (884345)2-54-00, 8-9276-778-776.**



**Арболитовые блоки, в наличии и под заказ.**
**Т. 8-9274-16-16-50.**



**ДВЕРИ ЭКОНОМ**
сеть дверных магазинов

Реклама

**ВХОДНЫЕ, МЕЖКОМНАТНЫЕ, БАННЫЕ ДВЕРИ.**
*АКЦИЯ! 10% СКИДКА НОВОСЕЛАМ!**
Цены г.Самары и Казани.
Ул. Гиматдинова, 52, 1 этаж (вход в БТИ).
**8-937-583-45-17, 8-927-439-17-06.**
**Акция действует с 24.08.15 по 31.10.15 г. Подробности в магазине. Организатор: ООО «Анира трэйд».*



«БАЛКОН СТ
НАМУСЛЫ ЭШ
Пластик, алюминий
* Рам өчен карка
(теләсә нин
* Балконнарны озы
һәм киңәйтә
* Тышлау, тәрәзә
козыреклa
* Күпьеллык тәҗри
һәм демон
* Килешүләрне өйгә к
% сыз бүлеп түләүне
Р.Р. тәкъдим
* Москит челтәре,
китерү һәм куеп би
* 5 ел гаран
Т.: 8-927-475-
8-917-896-1



**В АССОРТИ**
**КИРПИЧ, ГА**
**(ТЕПЛОН, УНИБЛО**
**ДОСТАВК**
**8-927-440-**

